# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Сайлау кодексына**
**үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Тавыш бирү көненә 21 яшькә җиткән граждан – Дәүләт Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, тавыш бирү көненә 18 яшькә җиткән граждан җирле үзидарәнең вәкиллекле органы депутаты булып сайланырга мөмкин (пассив сайлау хокукы).";

2) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

"$3^1$. Яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарына сайлаулар аны төзегән көннән соң алты айдан да соңга калмыйча уздырылырга тиеш.";

3) 7 статьяның 2 өлешендә "Сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда сайлау комиссияләре" сүзләрен "Сайлау комиссияләре" сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 статьяда:

а) 15 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль оешмалар, дәүләт һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары редакцияләре федераль законда, әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә комиссияләргә сайлаучыларга мәгълүмат бирү өчен түләүсез рәвештә эфир вакыты бирергә һәм комиссияләрнең карарларын бастырып чыгару, бүтән мәгълүматны урнаштыру өчен матбугат мәйданы бирергә тиеш.";

б) 16 өлештә "түләүсез" сүзен "бушлай" сүзенә алмаштырырга;

5) 11 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Сайлау комиссияләре Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрнең тәкъдимнәре нигезендә төзелә. Әлеге сайлау комиссияләрен төзү шулай ук "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" 2005 елның 18 маендагы 51-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" Федераль закон) $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр, әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр тәкъдимнәре, башка сәяси партияләр һәм бүтән иҗтимагый берләшмәләр тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.";

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

"$4^1$. Әлеге статьяның 3 һәм 4 статьяларында каралган хокукларга шулай ук "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр һәм әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр ия.";

6) 12 статьяда:

а) 3 өлештә "дүрт ел" сүзләрен "биш ел" сүзләренә алмаштырырга;

б) 7 өлештә:

1 пунктка ", шулай ук "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр" сүзләрен өстәргә;

2 пунктка ", шулай ук әлеге Кодексның 97[1] статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр" сүзләрен өстәргә;

7) 13 статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе вәкаләтләре шушы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы мөрәҗәгате нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән территория комиссиясенә йөкләнергә мөмкин. Яңа төзелгән муниципаль берәмлек оештырылган очракта, шулай ук муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы булмаган бүтән очракларда шушы муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе вәкаләтләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән территория комиссиясенә йөкләнергә мөмкин. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе вәкаләтләре территория комиссиясенә йөкләнгәндә, территория комиссиясе әгъзалары саны үзгәрмәскә тиеш. Әгәр муниципаль берәмлек территориясендә берничә территория комиссиясе төзелгән булса, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе вәкаләтләре шуларның берсенә йөкләнергә мөмкин.";

б) 5 өлештә "дүрт ел" сүзләрен "биш ел" сүзләренә алмаштырырга;

в) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6. Муниципаль районның, шәһәр округының сайлау комиссиясе хәлиткеч тавыш хокукына ия сигез, ун яисә унике әгъзадан төзелә. Җирлекнең сайлау комиссиясе хәлиткеч тавыш хокукына ия алты, сигез яисә ун әгъзадан төзелә. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе әгъзалары саны муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә.";

г) 7 өлештә ", территория комиссиясе" сүзләрен өстәргә;

д) 8 өлештә:

беренче абзацта "кимендә икедән берен" сүзләрен "яртысын" сүзенә алмаштырырга;

1 пунктка ", шулай ук "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" Федераль законның 82[1] статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр" сүзләрен өстәргә;

2 пунктка ", шулай ук әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр" сүзләрен өстәргә;

е) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9. Муниципаль районның, шәһәр округының вәкиллекле органы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясеннән алынган тәкъдимнәр нигезендә муниципаль районның, шәһәр округының сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан яртысын билгеләп куярга тиеш.";

ж) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ – $9^3$ өлешләр өстәргә:

"$9^1$. Җирлекнең вәкиллекле органы муниципаль районның сайлау комиссиясеннән, территория комиссиясеннән алынган тәкъдимнәр нигезендә җирлек сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан яртысын түбәндәге тәртиптә билгеләп куярга тиеш:

1) әгәр муниципаль районның сайлау комиссиясе вәкаләтләре территория комиссиясенә йөкләнмәгән булса, җирлек сайлау комиссиясенең ике әгъзасы муниципаль районның сайлау комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә билгеләп куела, җирлек сайлау комиссиясенең калган әгъзалары территория комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә билгеләп куела;

2) әгәр муниципаль районың сайлау комиссиясе вәкаләтләре территория комиссиясенә йөкләнгән булса, җирлек сайлау комиссиясе әгъзалары территория комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә билгеләп куела;

3) әгәр территория комиссиясе вәкаләтләре муниципаль районның сайлау комиссиясенә йөкләнгән булса, җирлек сайлау комиссиясе әгъзалары муниципаль районның сайлау комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә билгеләп куела.

$9^2$. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең, муниципаль районның сайлау комиссиясенең, территория комиссиясенең әлеге статьяның 9 һәм $9^1$ өлешләрендә күрсәтелгән тәкъдимнәре, әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән иҗтимагый берләшмәләрдән тыш, иҗтимагый берләшмәләрнең тәкъдимнәрен исәпкә алып, тору, эшләү, хезмәт, уку урынында сайлаучыларның җыелышлары тәкъдимнәрен, шулай ук тиешле муниципаль берәмлекнең узган составтагы сайлау комиссиясе тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнә.

$9^3$. Әлеге статьяның 8, 9 яисә $9^1$ өлешләрендә күрсәтелгән алынган тәкъдимнәр тиешенчә әлеге статьяның 8, 9 яисә $9^1$ өлешләрен гамәлгә ашыру өчен җитәрлек булмаган очракта, комиссиянең калган әгъзаларын билгеләп кую әлеге статьяның 7 өлешендә каралган тәкъдимнәр нигезендә гамәлгә ашырыла.";

8) 14 статьяда:

а) 5 өлештә:

1 пунктка ", шулай ук "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр" сүзләрен өстәргә;

2 пунктка ", шулай ук әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр" сүзләрен өстәргә;

б) 6 өлештә:

1 пунктка ", шулай ук "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр" сүзләрен өстәргә;

2 пунктка ", шулай ук әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр" сүзләрен өстәргә;

9) 15 статьяда:

а) 3 өлештә "дүрт ел" сүзләрен "биш ел" сүзләренә алмаштырырга;

б) 7 өлештә:

1 пунктка ", шулай ук "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр" сүзләрен өстәргә;

2 пунктка ", шулай ук әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр" сүзләрен өстәргә;

10) 16 статьяның 4 өлешендә:

а) 1 пунктка ", шулай ук "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр" сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктка ", шулай ук әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр" сүзләрен өстәргә;

11) 18 статьяда:

а) 13 өлешнең бишенче җөмләсен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $13^{1}$ һәм $13^{2}$ өлешләр өстәргә:

"$13^{1}$. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең анда даими нигездә (штатта) эшләүче әгъзасына, муниципаль берәмлекнең даими нигездә эш итүче һәм юридик зат булып торучы сайлау комиссиясенең анда даими нигездә (штатта) эшләүче әгъзасына түбәндәгеләр тыела:

1) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаса, Россия Федерациясе территориясендә эш итүче коммерциячел булмаган хөкүмәткә карамаган чит ил оешмаларының һәм аларның структур бүлекчәләренең идарә органнары, попечительләр һәм күзәтүчеләр советлары, бүтән органнары составына керү;

2) үзенә йөкләнгән Россия Федерациясе законнарында каралмаган вазыйфаларны башкаруга бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан бүләкләүләр (ссудалар, акчалата һәм бүтәнчә бүләкләү, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачулар һәм ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү) алу. Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә сайлау комиссиясе әгъзасы тарафыннан алынган бүләкләр тиешенчә Татарстан Республикасы милке, муниципаль милек итеп танылa һәм сайлау комиссиясе әгъзасы тарафыннан акт буенча тиешле сайлау комиссиясенә тапшырыла, моңа Россия Федерациясе законнарында каралган очраклар керми. Беркетмә чарасына, хезмәт командировкасына һәм башка рәсми чарага бәйле рәвештә алынган бүләген тапшырган сайлау комиссиясе әгъзасы шушы бүләкне Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин;

3) физик һәм юридик затлар акчалары исәбеннән үзенә йөкләнгән вазыйфаларны башкаруга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясеннән чыгып китү, моңа Россия Федерациясе законнары, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре яисә дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының чит илләрнең дәүләт органнары (органнары), халыкара һәм чит ил оешмалары белән үзара килешүләре нигезендә башкарыла торган хезмәт командировкалары керми;

4) үзенә йөкләнгән вазыйфаларны башкаруга бәйле булмаган максатларда хезмәт эшчәнлеге өчен билгеләнгән матди-техник, финанс һәм мәгълүмати тәэмин итү чараларыннан файдалану;

5) үзенә йөкләнгән вазыйфаларны башкаруга бәйле булмаган максатларда үзенә йөкләнгән вазыйфаларны башкаруга бәйле рәвештә аңа мәгълүм булган федераль закон белән файдалану чикләнгән мәгълүматка карый торган белешмәләрне яисә хезмәт мәгълүматын фаш итү яисә аннан файдалану.

$13^{2}$. Сайлау комиссиясенең әлеге статьяның $13^{1}$ өлешендә күрсәтелгән әгъзасы керем китерә торган кыйммәтле кәгазьләргә, акцияләргә (оешмаларның устав капиталларында катнашу өлешләренә) ия булу мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булган әлеге очракта, ул үзенеке булган әлеге кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав капиталларында катнашу өлешләрен) Россия Федерациясе законнары нигезендә ышанычлы идарәгә тапшырырга тиеш.";

12) 20 статьяда:

а) 4 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Даими нигездә эш итүче сайлау комиссиясенең сайланган кандидатлар тарафыннан, кандидатлар исемлекләре депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән сайлау берләшмәләре, кандидатларның федераль исемлекләренә "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган сәяси партияләр һәм әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә кандидатлар исемлекләренә депутат мандатлары тапшырылган сәяси партияләр тарафыннан билгеләнеп куелган киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының вәкаләтләре чоры шул ук органга яисә шул ук вазыйфага киләсе сайлауларда кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәү тәмамланганчы дәвам итә.";

б) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9. Сайланган кандидатларның, кандидатлар исемлекләре депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән сайлау берләшмәләренең, кандидатларның федераль исемлекләренә "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган сәяси партияләрнең һәм әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә кандидатлар исемлекләренә депутат мандатлары тапшырылган сәяси партияләрнең даими нигездә эш итүче сайлау комиссияләренең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларын билгеләп кую хокукы, шул исәптән киткәннәре урынына, депутатның, вазыйфаи затның вәкаләтләре чоры дәвамында саклана.";

13) 34 статьяның 3 өлешендә "сайлау берләшмәсе" сүзләрен "федераль закон нигезендә сайлауларда катнашу хокукына ия сәяси партия йә аның федераль закон нигезендә тиешле дәрәҗәдәге сайлауларда катнашу хокукына ия төбәк бүлеге яисә бүтән структур бүлекчәсе" сүзләренә алмаштырырга;

14) 37 статьяда:

а) 1 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

"$1^1$. Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда закон нигезендә теркәлгән, сәяси партияләр булып тормаган иҗтимагый берләшмәләр, аларның структур бүлекчәләре аларны сайлау берләшмәләре күрсәтә торган кандидатлар исемлекләренә кертү өчен кандидатуралар тәкъдим итәргә хокуклы. Мондый кандидатураларны кандидатлар

исемлекләренә кертү "Сәяси партияләр турында" Федераль законда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.";

в) 3 өлештә ", башка иҗтимагый берләшмә" сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 4 өлештә ", бүтән иҗтимагый берләшмә", ", башка иҗтимагый берләшмәнең" сүзләрен төшереп калдырырга;

15) 38 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"38 статья. **Гражданнарның пассив сайлау хокукын гамәлгә ашыру гарантияләре**

1. Барлык депутат мандатлары да кандидатлар исемлекләре арасында кандидатларның һәрбер исемлегендәге сайлаучыларның тавышлары санына пропорциональ бүленә торган муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына сайлаулар үткәргәндә, Россия Федерациясенең пассив сайлау хокукына ия һәр гражданы, депутатларны тиешле сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көннән алып өч көннән дә соңга калмыйча, теләсә кайсы сәяси партиянең теләсә кайсы региональ бүлегенә яисә башка структур бүлекчәсенә үзен шушы сәяси партия тарафыннан күрсәтелә торган кандидатлар исемлегенә кертү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Сәяси партия башка сәяси партияләрнең әгъзалары булып торучы Россия Федерациясе гражданнарын кандидатлар исемлекләрендәге составта кандидатлар итеп күрсәтергә хокуклы түгел.

2. Әлеге кандидатура сәяси партиянең кимендә ун әгъзасы тарафыннан хупланган очракта, ул сәяси партиянең региональ бүлегенең яисә башка структур бүлекчәсенең конференциясендә (гомуми җыелышында) кандидатлар исемлегенә кертүгә тәкъдим ителә торган башка кандидатуралар белән беррәттән кандидатлар исемлеген күрсәтү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә каралырга тиеш.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган мөрәҗәгатьләрнең булмавы сәяси партия тарафыннан үз инициативасы белән һәм үз уставы нигезендә әлеге сәяси партиянең әгъзасы булып тормаган Россия Федерациясе гражданын күрсәтелә торган кандидатлар исемлегенә кертү турында карар кабул итү өчен, шушы гражданның кандидатлар исемлеге составында чыгарылырга ризалыгы турында язма гаризасы булса, тоткарлык ясый алмый.

4. Сәяси партия әлеге статьяның 2 өлешендә каралган таләпләрне бозганда, федераль закон нигезендә җаваплылык билгеләнә.";

16) 39 статьяның 2 өлешендә "йә сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең структур бүлекчәсенең сәяси партия, бүтән иҗтимагый берләшмә уставы белән шуңа вәкаләт бирелгән даими эшләүче җитәкче органы" сүзләрен өстәргә;

17) 40 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән кандидатлар исемлеге белән бергә сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле түбәндәге документларны тапшыра:

1) сәяси партия уставының нотариаль таныкланган күчермәсен;

2) кандидатлар исемлеген күрсәтү турында сәяси партия съездының, башка вәкаләтле органының карарын (карарларын);

3) сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкилләре исемлеген, алар турында әлеге Кодексның 33 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә санап кителгән белешмәләрне күрсәтеп;

4) сайлау берләшмәсенең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләренә әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамәләрне;

5) кандидатлар исемлегенә кертелгән һәм сәяси партия әгъзалары булып торучы гражданнарның сәяси партиянең даими эшләүче җитәкче органы тарафыннан рәсми таныкланган исемлеген.

Әгәр "Сәяси партияләр турында" Федераль закон нигезендә кандидатлар исемлегенә сәяси партия булмаган иҗтимагый берләшмә тарафыннан яисә аның структур бүлекчәсе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатуралар кертелгән булса, сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясенә шулай ук әлеге иҗтимагый берләшмә уставының, "Сәяси партияләр турында" Федераль законның 26 статьясындагы $1^1$ пунктында каралган килешүнең нотариаль таныкланган күчермәсе һәм шушы килешү нигезендә кандидатлар исемлегенә кертелгән гражданнар исемлеге тапшырыла.";

б) 3 өлешнең 1 пунктындагы икенче җөмләсендә "йә сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең структур бүлекчәсенең сәяси партия, бүтән иҗтимагый берләшмә уставы белән шуңа вәкаләт бирелгән даими эшләүче җитәкче органы" сүзләрен өстәргә;

18) 41 статьяның 2 өлешендә "йә сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең структур бүлекчәсенең сәяси партия, бүтән иҗтимагый берләшмә уставы белән шуңа вәкаләт бирелгән даими эшләүче җитәкче органы" сүзләрен өстәргә;

19) 42 статьяның 2 өлешендәге 1 пунктның икенче җөмләсендә "йә сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең структур бүлекчәсенең сәяси партия, бүтән иҗтимагый берләшмә уставы белән шуңа вәкаләт бирелгән даими эшләүче җитәкче органы" сүзләрен өстәргә;

20) 43 статьяда:

а) исемендә "(тәэмин итү)" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтүне сайлаучылар, әлеге статьяның 2, $2^1$ һәм 3 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, имза кәгазьләренә үз имзаларын кертү юлы белән хупларга тиеш.";

в) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Кандидатларның федераль исемлеге моңа кадәр узган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларның рәсми басылып чыккан нәтиҗәләре нигезендә депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән (кандидатларның федераль исемлегенә "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандаты тапшырылган) сәяси партия, әгәр әлеге рәсми бастырып чыгару кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен кирәкле документлар сайлау комиссиясенә тапшырылганчы башкарылган булса, үзе күрсәткән кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен сайлаучылар имзаларын җыймаска хокуклы. Шулай ук кандидатлар исемлекләре Россия Федерациясенең кимендә өчтән бер субъектының сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә гамәлдә булган дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) органнарында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән (кандидатлар исемлекләренә "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 35 статьясындагы 17 пунктында каралган Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган) сәяси партия тарафыннан күрсәтелгән кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү һәм мондый сәяси партиянең региональ бүлекләре яисә башка структур бүлекчәләре (әгәр бу сәяси партия уставында каралган булса) тарафыннан күрсәтелгән кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәү дә сайлаучылар имзаларын җыймыйча гына гамәлгә ашырыла.";

г) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ һәм $2^2$ өлешләр өстәргә:

"$2^1$. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына сайлауларда, шулай ук җирле үзидарә органнарына сайлауларда кандидатлар исемлеге Дәүләт Советы депутатларын моңа кадәр узган сайлауларның рәсми басылып чыккан нәтиҗәләре нигезендә депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән (кандидатлар исемлегенә әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандаты тапшырылган) сәяси партия тарафыннан күрсәтелгән кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү, шулай ук мондый сәяси партиянең региональ бүлекләре яисә башка структур бүлекчәләре (әгәр бу сәяси партия уставында каралган булса) тарафыннан күрсәтелгән кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәү, әгәр күрсәтелгән рәсми бастырып чыгару кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен кирәкле документлар сайлау комиссиясенә тапшырылганчы башкарылган булса, сайлаучылар исемлекләрен җыймыйча гына гамәлгә ашырыла. Мондый

кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү бу кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтү турында федераль законда билгеләнгән тәртиптә сәяси партия, аның региональ бүлеге яисә башка структур бүлекчәсе тарафыннан кабул ителгән карар нигезендә гамәлгә ашырыла.

$2^2$. Әлеге статьяның $2^1$ өлешенең гамәли көче кагыла торган сәяси партияләрнең исемлеге Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелә, гомуми файдаланудагы "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз сайтында урнаштырыла һәм Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар нәтиҗәләре буенча яңартыла.";

д) татарча текст үзгәрми;

е) 6 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

21) 45 статьяда:

а) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 4 өлештә "43 статьясындагы 2 өлешендә" сүзләрен "43 статьясындагы 2 өлешендә яисә $2^1$ өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

в) 8 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

22) 46 статьяның 16 өлешендә "бер үк" сүзләреннән соң "кандидатны," сүзен өстәргә;

23) 47 статьяда:

а) 6 өлешнең 15 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 7 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) кандидатлар исемлеген күрсәтүгә карата "Сәяси партияләр турында" Федераль законда каралган таләпләрне үтәмәү, моңа күрсәтелгән Федераль законның 36 статьясындагы $3^1$ пунктында каралган таләпләр керми;";

7 пунктта "(әлеге Кодексның 67 статьясындагы 1 өлеше нигезендә сайлау фондын төзү мәҗбүри булмаган очрактан тыш)" сүзләрен төшереп калдырырга;

12 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

24) 48 статьяның 1 өлешендә "депутат статусына" сүзләрен "кандидат статусына" сүзләренә алмаштырырга;

25) 52 статьяның 1 өлешендә түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: "Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда бермандатлы сайлау округлары буенча кандидатлар күрсәткән сайлау берләшмәсе – 35кә кадәр, муниципаль сайлауларда бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча кандидатлар күрсәткән сайлау берләшмәсе 25кә кадәр ышанычлы зат билгеләп куярга хокуклы.";

26) 58 статьяның 8 өлешендәге 6 пунктында "4 статьясындагы 10 өлешендә" сүзләрен "4 статьясындагы 11 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

27) 60 статьяда:

а) 1 өлештә "түләүсез" сүзен "бушлай" сүзенә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ өлешләр өстәргә:

"$1^1$. Моңа кадәр узган тиешле сайлауларда тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 3 проценттан кимрәк тавышын җыйган һәм депутат мандатларын бүлешүгә кертелмәгән кандидатлар исемлеген йә сайланмаган һәм тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 3 проценттан кимрәк тавышын җыйган кандидатны күрсәткән сайлау берләшмәсе түләүсез эфир вакытыннан, түләүсез матбугат мәйданыннан файдаланырга хокуклы түгел. Мондый сайлау берләшмәсе түләүсез эфир вакытының, түләүсез матбугат мәйданының гомуми күләменнән үзенә тиешле өлешне яисә аның бер өлешен тиешле шартнамә нигезендә түләүле алырга хокуклы, ул түләүнең күләме сайлау алды агитациясен уздыру өчен дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләт һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары редакцияләре тарафыннан әлеге Кодексның 61 статьясындагы 9 өлеше һәм 62 статьясындагы 5 өлеше нигезендә резервлана торган түләү күләменнән артмаска тиеш. Әлеге өлештә каралган шартнамә нигезендә бирелә торган эфир вакытын һәм матбугат мәйданын бүлү түләүсез эфир вакытын, түләүсез матбугат мәйданын бүлү өчен әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырылырга тиеш.

$1^2$. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына сайлауларда кандидатларны һәм (яисә) кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсенә түләүсез эфир вакытын, түләүсез матбугат мәйданын бирүдән баш тарту мөмкин түгел, әгәр моңа кадәр узган сайлауларда:

а) бу сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлеге тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның әлеге Кодекста шушы статьяның $1^1$ өлеше нигезендә билгеләнгәннән кимрәк булмаган тавышлар санын җыйса;

б) сайлау берләшмәсе кандидатларны бары тик бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча гына күрсәткән булса.";

в) 9 өлештә "түләүсез" сүзен "бушлай" сүзенә алмаштырырга;

г) 11 өлештә "түләүле һәм түләүсез эфир вакытын" сүзләрен "эфир вакытын" сүзләренә алмаштырырга;

28) 61 статьяда:

а) 1 өлештә "түләүсез эфир вакыты" сүзләрен "түләүсез эфир вакыты, ә әлеге Кодексның 60 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән очракта, шулай ук түләүле эфир вакыты" сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Республика телерадиотапшырулар оешмалары теркәлгән кандидатларга, сайлау берләшмәләренә Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда сайлау алды агитациясен уздыру өчен әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытын бирергә тиеш. Муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары теркәлгән кандидатларга, сайлау берләшмәләренә җирле үзидарә органнарына сайлауларда сайлау алды агитациясен уздыру өчен әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытын бирергә тиеш. Бирелә торган эфир вакыты тиешле телерадиотапшырулар оешмасы тарафыннан билгеләнә торган теле- һәм радиотапшырулар күбрәк аудиторияне җыя торган вакытка туры килергә тиеш.";

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Һәр республика яисә муниципаль телерадиотапшырулар оешмасы сайлау алды агитациясен уздыру өчен бирә торган әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытының гомуми күләме эш көннәре буенча һәр каналда 30 минуттан да кимрәк булмаска тиеш, ә телерадиотапшырулар оешмасы тапшыруларының гомуми вакыты көнгә ике сәгатьтән кимрәк булса, – тапшыруларның гомуми вакытыннан дүрттән береннән кимрәк булмаска тиеш. Бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы буенча Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатын (депутатларын) өстәмә яисә кабат сайлауларда сайлау алды агитациясен уздыру өчен әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән телерадиотапшырулар оешмалары тарафыннан бирелә торган эфир вакытының гомуми күләме тиешле сайлау округында теркәлгән һәр кандидатка төп сайлауларда сайлау алды агитациясен уздыру өчен бирелгән түләүсез эфир вакытының күләменнән кимрәк булмаска тиеш. Әгәр һәр теркәлгән кандидатка, кандидатларның теркәлгән исемлеген күрсәткән һәр сайлау берләшмәсенә әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытын бирү нәтиҗәсендә эфир вакыты 60 минуттан артып китсә, агитация уздыру өчен һәр телерадиотапшырулар оешмасы бирә торган эфир вакытының гомуми күләме кыскартыла һәм ул, теркәлгән кандидатлар, кандидатларның теркәлгән исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләре санына тапкырлап, 60 минут тәшкил итәргә тиеш.";

г) 4 өлешнең беренче җөмләсендә "түләүсез эфир вакытының" сүзләрен "әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытының" сүзләренә алмаштырырга,

икенче җөмләсендә "түләүсез эфир вакытының" сүзләрен "әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытының" сүзләренә алмаштырырга;

д) 5 өлештә "түләүсез эфир вакытын" сүзләрен "әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытын" сүзләренә алмаштырырга;

е) 6 өлештә "Түләүсез эфир вакытының ... (ул булса)" сүзләрен "Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытының ... (ул булса)" сүзләренә алмаштырырга;

ж) 9 өлештә "түләүсез эфир вакытының" сүзләрен "әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытының" сүзләренә алмаштырырга;

29) 62 статьяның 12 өлешендә "түләүсез" сүзен "бушлай" сүзенә алмаштырырга;

30) 67 статьяда:

а) 5 – 12 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Дәүләт Советы депутатларына кандидатларның сайлау фондлары түбәндәгеләр исәбеннән төзелергә мөмкин:

1) кандидатның үз акчалары, аларның гомуми күләме хезмәт өчен түләүнең Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән 15 мең мәртәбәдән артыграк була алмый;

2) сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән кандидатка бирелгән акчалар, аларның гомуми күләме хезмәт өчен түләүнең Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән 15 мең мәртәбәдән артыграк була алмый;

3) гражданнарның иганәләре, аларның гомуми күләме хезмәт өчен түләүнең Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән һәр граждан өчен 300 мәртәбәдән артыграк була алмый;

4) юридик затларның иганәләре, аларның гомуми күләме хезмәт өчен түләүнең Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән һәр юридик зат өчен 12 мең мәртәбәдән артыграк була алмый.

6. Дәүләт Советы депутатына кандидатның сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләме хезмәт өчен түләүнең Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән 30 мең мәртәбәдән артыграк була алмый.

7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына сайлауларда кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләренең сайлау фондлары түбәндәгеләр исәбеннән төзелергә мөмкин:

1) сайлау берләшмәсенең үз акчалары, аларның гомуми күләме хезмәт өчен түләүнең Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән 150 мең мәртәбәдән артыграк була алмый;

2) гражданнарның иганәләре, аларның гомуми күләме хезмәт өчен түләүнең Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән һәр граждан өчен 300 мәртәбәдән артыграк була алмый;

3) юридик затларның иганәләре, аларның гомуми күләме хезмәт өчен түләүнең Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән һәр юридик зат өчен 12 мең мәртәбәдән артыграк була алмый.

8. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына сайлауларда кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсенең сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләме хезмәт өчен түләүнең Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән 300 мең мәртәбәдән артыграк була алмый.

9. Депутатлыкка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларына кандидатларның сайлау фондлары түбәндәгеләр исәбеннән төзелергә мөмкин:

1) кандидатның үз акчалары, аларның гомуми күләме хезмәт өчен түләүнең муниципаль сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән 3 мең мәртәбәдән артыграк була алмый;

2) кандидатка аны күрсәткән сайлау берләшмәсе тарафыннан бүлеп бирелгән акчалар, аларның гомуми күләме хезмәт өчен түләүнең муниципаль сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән 3 мең мәртәбәдән артыграк була алмый;

3) гражданнарның иганәләре, хезмәт өчен түләүнең муниципаль сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән һәр граждан өчен 150 мәртәбәдән артыграк булмаган күләмдә;

4) юридик затларның иганәләре, хезмәт өчен түләүнең муниципаль сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән һәр юридик зат өчен 3 мең мәртәбәдән артыграк булмаган күләмдә.

10. Депутатлыкка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларына кандидатның сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләме хезмәт өчен түләүнең муниципаль сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән 6 мең мәртәбәдән артыграк була алмый.

11. Муниципаль сайлауларда кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләренең сайлау фондлары, муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидатның сайлау фонды түбәндәгеләр исәбеннән төзелергә мөмкин:

1) кандидатлар исемлеген, муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидат күрсәткән сайлау берләшмәсенең үз акчалары, муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидатның үз акчалары, аларның гомуми күләме хезмәт өчен түләүнең муниципаль сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән 30 мең мәртәбәдән артыграк була алмый;

2) гражданнарның иганәләре, хезмәт өчен түләүнең муниципаль сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән һәр граждан өчен 300 мәртәбәдән артыграк булмаган күләмдә;

3) юридик затларның иганәләре, хезмәт өчен түләүнең муниципаль сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән һәр юридик зат өчен 3 мең мәртәбәдән артыграк булмаган күләмдә.

12. Муниципаль сайлауларда кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсенең сайлау фонды, муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидатның сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләме хезмәт өчен түләүнең муниципаль сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән 60 мең мәртәбәдән артыграк була алмый.";

б) 14 өлешнең 2 пунктында "4 статьясындагы 10 өлешендә" сүзләрен "4 статьясындагы 11 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

31) 70 статьяның 3 өлешендәге 4 пунктын һәм 11 өлешен үз көчләрен югалткан дип танырга;

32) 71 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

33) 73 статьяның 3 өлешендәге 4 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

34) 74 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш өстәргә:

"10. Әлеге Кодексның $128^1$ статьясындагы 1 өлеше нигезендә кабат тавыш бирү үткәрелергә мөмкин булган очракта, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгының өзмә талоны булырга тиеш. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы, аңа сайлаучының фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм сайлаучы яшәү урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогының номеры кертелгән булса һәм шушы бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгында тиешле участок комиссиясенең ике мөһере һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын биргән тиешле сайлау комиссиясе әгъзасының ике имзасы булса, дөрес дип санала, бу чакта бер мөһер һәм бер имза өзмә талонда торырга тиеш.

Гомуми сайлауларда тавыш бирү үткәргәндә, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы күрсәткән сайлаучыдан өзмә талон алып калына.";

35) 75 статьяның 6 өлешендәге 8 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

36) 81 статьяда:

а) 2 өлештә "116 статьясындагы 2 өлешендә" сүзләреннән соң ", $128^1$ статьясындагы 3 һәм 13 өлешләрендә" сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

"5. Әлеге Кодекс нигезендә депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән һәр кандидатлар исемлегенә кимендә бер депутат мандаты бүленергә тиеш.";

37) 97 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ өлеш өстәргә:

"$7^1$. Депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатларның республика исемлекләреннән тыш, депутат мандатларын тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 7 процenttан кимрәк, әмма 5 процenttан да кимрәк булмаган тавышларын җыйган һәм депутат мандатларын бүлешүгә кертелмәгән кандидатларның республика исемлекләре ала. Кандидатларның мондый республика исемлекләренә әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырыла.";

б) 9 өлештә "98 статьясындагы 6 өлешендә" сүзләрен "$97^1$ статьясындагы 4 өлешендә яисә 98 статьясындагы 6 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

38) түбәндәге эчтәлекле $97^1$ статья өстәргә:

"$97^1$ статья. **Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 7 процenttан кимрәк, әмма 5 процenttан да кимрәк булмаган тавышларын җыйган һәм депутат мандатларын бүлешүгә кертелмәгән кандидатларның республика исемлекләренә депутат мандатларын тапшыру**

1. Әлеге Кодексның 98 статьясы нигезендә депутат мандатларын бүлешкәнче, депутат мандатлары тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 7 процenttан кимрәк, әмма 5 процenttан да кимрәк булмаган тавышларын җыйган һәм депутат мандатларын бүлешүгә кертелмәгән кандидатларның республика исемлекләренә тапшырыла.

2. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 7 процenttан кимрәк, әмма 5 процenttан да кимрәк булмаган тавышларын җыйган һәм депутат мандатларын

бүлешүгә кертелмәгән кандидатларның республика исемлегенә бер депутат мандаты тапшырыла.

3. Әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә кандидатларның республика исемлегенә тапшырылган депутат мандаты кандидатларның республика исемлегенә кертелгән чиратлылык тәртибендә беренче теркәлгән кандидатка күчә.

4. Әгәр тапшырылган депутат мандаты вакантлы булып чыкса, ул кандидатларның республика исемлегенә кертелгән теркәлгән кандидатлар арасыннан чиратлылык тәртибендә беренче теркәлгән кандидатка күчә.

5. Әгәр депутат мандатын тапшыру барышында кандидатларның республика исемлегендә вакантлы депутат мандатын биләү хокукына ия теркәлгән кандидатлар калмаса, бу депутат мандаты Дәүләт Советы депутатларын киләчәк төп сайлауларга кадәр вакантлы булып кала.";

39) 98 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: "Әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә кандидатларның республика исемлекләренә депутат мандатларын тапшырган очракта, сайлаучылар тавышларының күрсәтелгән суммасы тапшырудан соң калган депутат мандатлары санына бүленә.";

б) 5 өлешнең икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Депутат мандатларын тапшыру кандидатларның һәр исемлеге өчен депутат мандатларын өстәмә бүлешүнең тиешле кандидатлар исемлеге алган депутат мандатларының гомуми санын шушы ук исемлек җыйган сайлаучылар тавышлары санына бүлү юлы белән исәпләп чыгарылган коэффициентлары нигезендә башкарыла.";

в) 8 өлешнең икенче җөмләсенә "(әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә алынган депутат мандатларын исәпкә алып)" сүзләрен өстәргә;

40) 100 статьяның 2 өлешендә "98 статьясындагы 6 өлешендә" сүзләрен "$97^1$ статьясындагы 4 өлешендә яисә 98 статьясындагы 6 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

41) 103 статьяда:

а) 1 өлештә "98 статьясындагы 6 өлеше" сүзләрен "$97^1$ статьясындагы 4 өлеше яисә 98 статьясындагы 6 өлеше" сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

"3. Әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандаты тапшырылган кандидатларның республика исемлегендә вакантлы депутат мандатын биләү хокукына ия теркәлгән кандидатлар калмаса, бу депутат мандаты Дәүләт Советы депутатларын киләчәк төп сайлауларга кадәр вакантлы булып кала.";

42) 113 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Сәяси партияләр тарафыннан кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен күрсәтү "Сәяси партияләр турында" Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла. Башка иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан кандидатлар күрсәтү шушы иҗтимагый берләшмәләрнең, аларның региональ яисә җирле бүлекчәләренең съездларында (конференцияләрендә, җыелышларында) яшерен тавыш бирү юлы белән, шулай ук кандидатлар күрсәтүгә сәяси партияләр өчен федераль закон белән куела торган башка таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла.";

43) 118 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: "Аннары, бер депутат мандаты да алмаган кандидатларның исемлекләре булса, бүленмәгән депутат мандатлары күрсәтелгән кандидатлар исемлекләренә берәмләп тапшырыла. Кандидатларның шушы исемлекләре әлеге статьяның 3 өлеше нигезендә депутат мандатларын икенчел бүлешкәндә катнашмыйлар.";

б) 5 өлешнең икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Депутат мандатларын тапшыру кандидатларның һәр исемлеге өчен депутат мандатларын өстәмә бүлешүнең тиешле кандидатлар исемлеге алган депутат мандатларының гомуми санын шушы ук исемлек җыйган сайлаучылар тавышлары санына бүлү юлы белән исәпләп чыгарылган коэффициентлары нигезендә башкарыла.";

44) 21 бүлектә:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"21 бүлек. **Кабат тавыш бирү һәм кабат сайлаулар**";

б) түбәндәге эчтәлекле $128^1$ статья өстәргә:

"$128^1$ статья. **Кабат тавыш бирү**

1. Кабат тавыш бирү теркәлгән кандидатны сайланган дип тануның әлеге Кодексның 114 статьясындагы 3 өлешенең 2 – 4 пунктларында, 126 статьясындагы 2 өлешенең 1, 2 пунктларында каралган шартларыннан берсе муниципаль берәмлек уставында билгеләнгән очракларда үткәрелергә мөмкин. Кабат тавыш бирү "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон, әлеге Кодекс таләпләрен үтәгән килеш, әлеге статьяда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә.

2. Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе, тиешле гомуми сайлауларда бюллетеньгә икедән артыграк теркәлгән кандидат кертелгән һәм шуларның берсе дә гомуми сайлаулар нәтиҗәләре буенча сайлану өчен кирәкле сайлаучылар тавышлары санын җыймаган очракта, кабат тавыш бирү билгели. Кабат тавыш бирү

сайлаучылар тавышларының иң күп санын җыйган ике теркәлгән кандидат буенча үткәрелә, бу чакта һәр теркәлгән кандидатның үз кандидатурасы буенча кабат тавыш бирү үткәрүгә ризалыгы турында язма гаризасы булырга тиеш.

3. Гомуми сайлауларда бюллетеньгә ике кандидат кертелсә һәм шуларның берсе дә сайлану өчен кирәкле сайлаучылар тавышлары санын җыймаса, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе сайлауларны булмаган дип таный.

4. Кабат тавыш бирү гомуми сайлауларда тавыш биргән көннән соң 21 көн узгач үткәрелә. Кабат тавыш бирү үткәрү турындагы хәбәр, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе тиешле карар кабул иткән көннән ике көннән дә соңга калмыйча, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

5. Кабат тавыш бирү үткәргәнче кабат тавыш бирү үткәрелергә тиешле теркәлгән кандидатлардан берәрсе үз кандидатурасын алса яисә башка сәбәпләр аркасында киткән булса, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе карары буенча аның урыны җыелган тавышлар саны буенча муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе башта кабат тавыш бирү билгеләгән кандидатуралардан соң килүче кандидатка тапшырыла, бу чакта әлеге теркәлгән кандидатның үз кандидатурасы буенча кабат тавыш бирү үткәрүгә ризалыгы турында язма гаризасы булырга тиеш. Мондый гариза башта кабат тавыш бирү билгеләнгән кандидат киткән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча бирелергә тиеш. Бу очракта кабат тавыш бирү әлеге Кодексның 53 статьясындагы 1 өлеше нигезендә гариза биргән көннән йә кандидат башка сәбәпләр аркасында киткән көннән соң 14 көн узгач беренче якшәмбедә үткәрелә.

6. Кабат тавыш бирү үткәргәндә кандидатуралары буенча кабат тавыш бирү үткәрелми торган теркәлгән кандидатлар муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе кабат тавыш бирү датасын билгеләгән көннән үз статусын югалта. Бу чакта, әлеге статьяның 5 өлешендә каралган очракта, киткән теркәлгән кандидат урынын биләгән теркәлгән кандидат теркәлгән кандидат статусына бәйле хокукларга һәм бурычларга яңадан ия була.

7. Кабат тавыш бирү үткәргәндә агитация чоры муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе кабат тавыш бирү көнен билгеләгән көннән яңартыла.

8. Сайлау фонды акчаларын тотуның әлеге Кодексның 67 статьясындагы 9 – 13 өлешләрендә билгеләнгән иң чик күләме һәм кабат тавыш бирү билгеләнгән кандидатның үз акчаларының иң чик күләме тиешенчә 25 һәм 50 процентка арттырыла.

9. Кабат тавыш бирү үткәргәндә бюллетень тексты, бюллетеньнәр саны кабат тавыш бирү үткәрү турындагы карар кабул итү белән бер үк вакытта муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Бу чакта бюллетеньдә сайлаучылар тавышларының иң күп санын җыйган теркәлгән кандидат фамилиясе беренче итеп урнаштырыла.

10. Кабат тавыш бирү үткәрелгән очракта, сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогының тавыш бирү урынына тавыш бирү көнендә килү мөмкинлеге булмаган сайлаучы муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе кабат тавыш бирү билгеләгән көннән алып кабат тавыш бирү көненнән алдагы көнгә кадәр чорда тиешле участок комиссиясендә өзмә талоннан башка гына бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы алырга хокуклы. Кабат тавыш бирү үткәргәндә

бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы күрсәткән сайлаучыдан бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы алып калына. Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе кабат тавыш бирү билгеләгән көннән алып кабат тавыш бирү көненнән алдагы көнгә кадәр чорда сайлаучыларга бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларының кулланылмаган өзмә талоннары юкка чыгарыла. Кабат тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты җиткәнче кулланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары өзмә талоннары белән бергә юкка чыгарыла. Тиешле участок комиссиясе кулланылмаган өзмә талоннарны һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын шушы талоннарны һәм таныклыкларның санын күрсәтеп юкка чыгара. Актта күрсәтелгән юкка чыгарылган кулланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклыкларының саны әлеге Кодексның 79 статьясындагы 3 өлеше нигезендә сайлаучылар тавышларын санаганда игълан ителә. Кабат тавыш бирү көненә кадәр сайлау участогында сайлаучыларга өзмә талоннарсыз гына бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны һәм юкка чыгарылган кулланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны тиешенчә участок комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәсенең 11 һәм 13 юлларында күрсәтелә. Тавышларны санаганда катнашучы әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затлар юкка чыгарылган өзмә талоннар һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары белән участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тикшереп торган килеш визуаль танышырга хокуклы.

11. Тавыш биргәндә башка кандидат тарафыннан җыелган сайлаучылар тавышлары санына карата сайлаучылар тавышларының иң күп санын җыйган кандидат кабат тавыш бирү йомгаклары буенча сайланган дип санала.

12. Теркәлгән кандидатлар төшеп калганнан соң бары тик бер генә теркәлгән кандидат калса, кабат тавыш бирү бер кандидатура буенча гына үткәрелергә мөмкин. Мондый чакта, теркәлгән кандидат тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар тавышының кимендә 50 процентын җыйган булса, ул сайланган дип санала.

13. Әгәр кабат тавыш бирү бер кандидатура буенча үткәрелсә һәм тиешле кандидат өчен тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар саныннан кимендә 50 проценты тавыш бирсә йә кабат тавыш бирү үткәргәндә барлык кандидатлар да төшеп калса, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе тиешле сайлауларны узмаган дип таный.";

45) 131 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Сайлау кодексының (әлеге Закон редакциясендә) 12 статьясындагы 3 өлешенең, 13 статьясындагы 5 өлешенең һәм 15 статьясындагы 3 өлешенең сайлау комиссияләре вәкаләтләре срогына кагыла торган нигезләмәләре

әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң төзелгән тиешле сайлау комиссияләренә карата кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 28 июне
№ 33-ТРЗ